**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры сораулары җаваплары 2017-2018 уку елы. 6 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты - 90 минут**
**максималь балл - 62**

**I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Ирен гармониясе чагылыш тапкан сүз кулланылган җөмләне билгеләгез. (2 балл)

а) Ноябрь узды, ә кар һаман төшми дә төшми. (Ә.Еники)

ә) Быел, әйтергә кирәк, караңгы көз дә бик озакка сузылган иде. (Ә.Еники)

б) Бераз сүзсез торганнан соң, солдат сорап куйды. (Ф.Хөсни)

**в) Шушы соравыма җавап табарга теләп, беркөнне мин урманга киттем. (Ф.Яруллин)**

2. Җөмләдәге ТСТ калыбына туры килгән иҗекләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Яңгырдан соң кояш бар, алдаудан соң оят бар.* (Мәкаль)

а) 7;

ә) 8;

**б) 11;**

в) 12.

3. Яңгыраулыкта һәм саңгыраулыкта ярашу күренеше чагылыш тапмаган җөмләне билгеләгез. (2 балл)

а) Хәсән Туфан әсәрләрендә хезмәт халкын зурлады. (Г.Бәширов)

ә) Үләннәр корыган, яфраклар саргайган, җил ыжгыра. (Ш.Камал)

б) Менә, сызылып кына, җәйге таң ата. (Г.Галиев)

**в) Юк, учлап карамыйча булмый иде бу беренче карны! (Ә.Еники)**

4. Архаизмнардан гына торган рәтне билгеләгез. (2 балл)

а) әчмуха, гөрәнкә, кистән, чулпы;

**ә) гакыл, өмит, ошбу, инану;**

б) имидж, факс, сканер, рэп;

в) авызга су кабу, салам кыстыру, җил куу, ут йоту.

5. Фразеологик әйтелмәнең мәгънәсе дөрес аңлатылган рәтне билгеләгез. (2 балл)

***Коры кул белән калу***

**а) алдану;**

ә) бер кулсыз калу;

б) әйберне урлагач тотылмау;

в) дусларсыз калу.

6. Исем ясагыч кушымчалардан гына торган рәтне билгеләгез. (2 балл)

а) -ның/-нең, -ны/-не, -га/-гә, -дан/-дән;

ә) -ым/-ем, -ың/-ең, -ы/-е, -ыбыз/-ебез;

**б) -ыш/-еш, -лык/-лек, -как/-кәк, -ак/-әк;**

в) -ык/-ек, -чыл/-чел, -гыр/-гер, -сыз/-сез.

7. Мәкальдәге калын хәрефләр белән бирелгән исемнең үзенчәлекләре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Теле озын **кешенең** акылы кыска булыр.*

а) уртаклык исем, ясалма, берлек санда, тартым белән төрләнмәгән, иялек килешендә;

**ә) уртаклык исем, тамыр, берлек санда, тартым белән төрләнмәгән, иялек килешендә;**

б) уртаклык исем, тамыр, берлек санда, тартым белән төрләнгән, иялек килешендә;

в) уртаклык исем, тамыр, берлек санда, тартым белән төрләнмәгән, төшем килешендә.

8. Эндәш сүз кулланылган җөмләне билгеләгез. (2 балл)

а) Иртә белән яктырганны көтеп ятма! (Г.Бәширов)

ә) Карның күзе буламыни? (Р.Төхфәтуллин)

б) Ә син нигә куанасың? (В.Бианки)

**в) Я, ниләр күрдегез, кунаклар? (М.Әмир)**

9. Тиңдәш кисәкләре бүлүче теркәгечләр белән бәйләнгән җөмләне билгеләгез. (2 балл)

а) Иркәли һәм сөя кояшның яктысы. (Г.Тукай)

**ә) Әллә күпкә, әллә бик озакка, ахры, мәңге оныта алмамын. (Һ.Такташ)**

б) Утта янмый, суда батмый. (Табышмак)

в) Көз инде кырларга да, аланнарга да килде. (Г.Хәсәнов)

10. Тойгылы җөмләне билгеләгез. (2 балл)

а) Идел дә шундый зурмы, эти? (Г.Гобәй)

ә) Яшел төс ул – яшәү төсе. (Мөҗәһит)

б) Исегездән чыкмасын бүгенге көн! (Ч.Айтматов)

**в) Мондый мул, сихри яктылык ап-ак кышта гына була! (Д.Гайнетдинова)**

## II. Башыгызны эшләтегез.

Урман сүзеннән 10 яңа сүз ясагыз. (урманчы, урманчылык, урманлы, урмансыз, урмандагы, урманчылыктагы, урманчыдагы, урманчысыз, урманчылы, урманлык) (10 балл)

## III. Теоретик бирем.

Көнбатыш диалект турында белгәннәрегезне язгыз, фикерегезне мисаллар ярдәмендә дәлилләгез. (10 балл)

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

*Эшле кеше – көчле кеше.* (Мәкаль)

1. *Көчле* сүзенә фонетик анализ ясагыз. (5 балл)
2. *Кеше* сүзенә лексик анализ ясагыз. (3 балл)
3. *Эшле* сүзенә морфологик анализ ясагыз. (3 балл)
4. Җөмләнең иясен билгеләгез. (1 балл)
5. Әлеге тема белән бәйле фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. (10 балл)

Текст язуга таләпләр:
- текст төзелеше ( башлам, төп өлеш, йомгаклау);
- җөмләләр дөрес, төзек булырга тиеш;
- язма телнең  бай, сурәтле булуына  игътибар итәргә;
- орфографик грамоталылыкка игътибарлы булырга.